**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422640, с. Большая Елга,
ул.Октябрьская, дом 25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ ЕЛГА**
**АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

422640, Олы Елга ав.,
Октябрь урамы, 25 йорт

Тел.: (84361) 25-264, факс: (84361) 25-265, эл.адрес: Belg.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 22 июле Олы Елга ав. № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Елга авылы һәм Сорочьи Горы авыл торак пунктларында гражданнар җыенын билгеләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе, Олы Елга авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге LXIII-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 4.4 пункты нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Олы Елга авылы гражданнарының 2021 елның 30 ноябрендә узган халык җыенының 1 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Олы Елга авылы халкы җыенының беренче этабын 2022 елның 3 августына 9 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Олы Елга авылы гражданнарының 2021 елның 30 ноябрендә узган халык җыенының 1 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Олы Елга авылы халкы җыенының икенче этабын 2022 елның 3 августына 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3. Сорочьи Горы авылы гражданнарының 2021 елның 30 ноябрендә узган халык җыенының 1 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сорочьи Горы авылы халкы җыенын 2022 елның 3 августына 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез гражданнар җыенының 2021 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә ризамы?:

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә үзара салым акчалары тотыла торган эш төрләре исемлегенә түбәндәге пунктларны кертергә:

- Олы Елга авылында зиратка илтүче юлларны төзекләндерү (вак таш сатып алу, таш ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтү, ташны җәю, эш өчен түләү);

- Казаклар авылы балалар мәйданчыгы территориясен койма (киртә, рәшәткә) белән әйләндереп алу (материал сатып алу, шартнамә нигезендә эшләр өчен түләү);

- елның салкын вакытында җир эшләре өчен вата торган чүкеч һәм кискеч (зубило) сатып алу.”

5. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам, 16а йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

6. Карар басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Ф.А.Садриев